| КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ |
|---|---|---|

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2018 ел, 4 сентябрь г.Казань № 746

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Агросәнәгать комплексына Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән дәүләт ярдәме күрсәтү чаралары турында» 2018 ел, 26 гыйнвар, 42 нче карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Агросәнәгать комплексына Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән дәүләт ярдәме күрсәтү чаралары турында» 2018 ел, 26 гыйнвар, 42 нче карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2018 ел, 5 март, 137 нче карары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1 нче пунктка түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«Авыл хуҗалыгы товарлары җитештерүчеләргә сөт комплекслары төзелешенә проект-смета документларын проектлаштыруга һәм аларга дәүләт экспертизасы үткәрүгә бәйле чыгымнарның бер өлешен каплау өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибен.»;

әлеге карар белән расланган Авыл хуҗалыгы товарлары җитештерүчеләргә Татарстан Республикасында орлыкчылыкны үстерүне яхшыртуга юнәлдерелгән чаралар буенча чыгымнарның бер өлешен каплау өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибендә 4 нче пунктның өченче абзацында һәм 11 нче пунктның дүртенче абзацында «үзгәртеп оештыру,» сүзләрен төшереп калдырырга;

әлеге карар белән расланган Авыл хуҗалыгы товарлары җитештерүчеләргә мелиорация эшләре үткәрүгә бәйле чыгымнарның бер өлешен каплау өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибендә 4 нче

пунктның өченче абзацында һәм 6 нчы пунктның дүртенче абзацында «үзгәртеп оештыру,» сүзләрен төшереп калдырырга;

әлеге карар белән расланган Җәнлек үрчетү хуҗалыкларына читлектәге кыйммәтле мех бирә торган җәнлекләрне карап тоту чыгымнарының бер өлешен каплауга Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибендә 4 нче пунктның «б» пунктчасындагы өченче абзацта һәм 6 нчы пунктның дүртенче абзацында «үзгәртеп оештыру,» сүзләрен төшереп калдырырга;

әлеге карар белән расланган Нәселле терлекчелеккә булышлык күрсәтүгә Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибендә 7 нче пунктның өченче абзацында һәм 29 нчы пунктның дүртенче абзацында «үзгәртеп оештыру,» сүзләрен төшереп калдырырга;

әлеге карар белән расланган Мелиорация объектларын яңадан техник җиһазландыруга Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибендә 4 нче пунктның өченче абзацында һәм 6 нчы пунктның дүртенче абзацында «үзгәртеп оештыру,» сүзләрен төшереп калдырырга;

әлеге карар белән расланган Авыл хуҗалыгы товарлары җитештерүчеләрнең аграр юнәлештәге квалификацияле белгечләр әзерләүгә бәйле чыгымнарының бер өлешен каплау өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибендә 4 нче пунктның өченче абзацында һәм 6 нчы пунктның дүртенче абзацында «үзгәртеп оештыру,» сүзләрен төшереп калдырырга;

әлеге карар белән расланган Авыл хуҗалыгы әзерләү-куллану кооперативларының, әзерләү оешмалары һәм кулланучылар кооперациясе предприятиеләренең ит, йон һәм күн чималын сатып алу, эшкәртү һәм сату чыгымнарының бер өлешен каплау өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибендә 4 нче пунктның өченче абзацында һәм 6 нчы пунктның дүртенче абзацында «үзгәртеп оештыру,» сүзләрен төшереп калдырырга;

әлеге карар белән расланган Авыл хуҗалыгы товарлары җитештерүчеләргә (шәхси ярдәмче хуҗалык алып баручы гражданнардан тыш), оештыру-хокукый формаларына бәйсез рәвештә агросәнагать комплексы оешмаларына, крестьян (фермер) хуҗалыкларына оешмалар мөлкәтенә салым түләү белән бәйле чыгымнарның бер өлешен каплау өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибендә:

4 нче пунктта:

икенче абзацта «гамәлдәге бәяләрдә» сүзләрен «чагыштырма бәяләрдә (үткән ел өчен фактта гамәлдәге бәяләрдә)» сүзләренә алыштырырга;

өченче абзацта «дуңгызчылык предприятиеләре» сүзләрен «дуңгызчылык, кошчылык предприятиеләре һәм шикәр заводлары» сүзләренә алыштырырга;

5 нче пунктның өченче абзацында «үзгәртеп оештыру,» сүзләрен төшереп калдырырга;

6 нчы пунктта:

дүртенче абзацта «үзгәртеп оештыру,» сүзләрен төшереп калдырырга;

тугызынчы абзацта «гамәлдәге бәяләрдә» сүзләрен «чагыштырма бәяләрдә (үткән ел өчен фактта гамәлдәге бәяләрдә)» сүзләренә алыштырырга;

унынчы абзацта «дуңгызчылык предприятиеләре» сүзләрен «дуңгызчылык, кошчылык предприятиеләре һәм шикәр заводлары» сүзләренә алыштырырга;

әлеге карар белән расланган Авыл хуҗалыгы ярминкәләрендә катнашкан авыл хуҗалыгы товарлары җитештерүчеләргә, кулланучылар җәмгыятьләренә, агросәнәгать комплексы оешмаларына, индивидуаль эшмәкәрләргә һәм шәхси ярдәмче хуҗалык алып баручы гражданнарга ягулык-майлау материалларына чыгымнарын каплау өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибендә 4 нче пунктның өченче абзацында һәм 6 нчы пунктның дүртенче абзацында «үзгәртеп оештыру,» сүзләрен төшереп калдырырга;

әлеге карар белән расланган Кулланучылар кооперацияләре оешмаларына күчмә сәүдәне гамәлгә ашыру өчен махсус автотранспорт сатып алу белән бәйле чыгымнарының бер өлешен каплау өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибендә 4 нче пунктның өченче абзацында һәм 6 нчы пунктның дүртенче абзацында «үзгәртеп оештыру,» сүзләрен төшереп калдырырга;

әлеге карар белән расланган Агросәнәгать комплексы өлкәсендә фәнни тикшеренүләргә һәм эшләргә дәүләт ярдәме күрсәтү өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан грантлар бирү тәртибендә 3.2.2 нче пунктның өченче абзацында һәм 5.3.1 нче пунктның икенче абзацында «үзгәртеп оештыру,» сүзләрен төшереп калдырырга;

әлеге карар белән расланган Үсемлекчелекне үстерүгә юнәлдерелгән чаралар чыгымнарының бер өлешен каплау өчен авыл хуҗалыгы товар җитештерүчеләренә Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибендә:

1 нче пунктка түбәндәге эчтәлекле «г» пунктчасы өстәргә:

«г) минераль ашламалар активаторларын сынауга.»;

3 нче пунктта:

өченче абзацта «авыл хуҗалыгы культураларының чәчү мәйданнары» сүзләреннән соң «һәм (яки) ябык грунт яшелчәләре биләгән мәйданнары» сүзләрен өстәргә;

түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«бу Тәртипнең 1 нче пунктындагы «г» пунктчасында күрсәтелгән субсидияләр алу өчен – агымдагы финанс елында минераль ашламалар активаторларын кулланып ашланган чәчү мәйданнары булу.»;

4 нче пунктның өченче абзацында һәм 8 нче пунктның дүртенче абзацында «үзгәртеп оештыру,» сүзләрен төшереп калдырырга;

Тәртипкә түбәндәге эчтәлекле яңа $7^1$ нче пункт өстәргә:

«$7^1$. Алучыга минераль ашламалар активаторларын сынауны үткәрүгә субсидия, өстәлгән кыйммәткә салымны һәм транспорт чыгымнарын исәпкә алмыйча, сатып алу кыйммәтенең 95 проценты күләмендә бирелә »;

8 нче пунктның беренче абзацында «5 – 7» саннарын «5 – $7^1$» саннарына алыштырырга;

Тәртипкә түбәндәге эчтәлекле яңа $11^1$ нче пункт өстәргә:

«$11^1$ Бу Тәртипнең $7^1$ нче пунктында күрсәтелгән субсидияләр алу өчен алучылар Идарәгә өстәмә рәвештә түбәндәгеләрне тапшыра:

минераль ашламалар активаторларын кайтарту шартнамәсе күчермәсен (агымдагы финанс елында ашламалар алуны раслый торган);

минераль ашламалар активаторларына түләүне раслый торган түләү йөкләмәсе күчермәсен;

минераль ашламалар активаторларын сатып алуга товар-транспорт йөкнамәләре күчермәсен;

минераль ашламалар активаторларын куллану актын.

Бирелгән документларның күчермәләре субсидияләр алучылар тарафыннан раслана.»;

12 нче пунктның дүртенче абзацында «8 – 11» саннарын «8 – $11^1$» саннарына алыштырырга;

14 нче пунктта:

өченче абзацта «ябык грунт яшелчәләре мәйданы» сүзләрен «агымдагы финанс елында ябык грунт яшелчәләре билгән мәйдан булу» сүзләренә алыштырырга;

түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«бу Тәртипнең $7^1$ нче пунктында күрсәтелгән субсидия алу өчен минераль ашламалар активаторларын кулланып ашланган чәчү мәйданы.»;

әлеге карарга Авыл хуҗалыгы товарлары җитештерүчеләргә сөт комплекслары төзелешенә проект-смета документларын проектлаштыруга һәм аларга дәүләт экспертизасы үткәрүгә бәйле чыгымнарның бер өлешен каплау өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибен (карарга теркәлә) өстәргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2018 ел, 26 гыйнвар, 42 нче
карары белән расланды
(Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2018 ел, 4 сентябрь, 746 нчы
карары редакциясендә)

Авыл хуҗалыгы товарлары җитештерүчеләргә сөт комплекслары
төзелешенә проект-смета документларын проектлаштыруга һәм аларга
дәүләт экспертизасы үткәрүгә бәйле чыгымнарның бер өлешен каплау өчен
Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү
тәртибе

1. Бу Тәртип авыл хуҗалыгы товарлары җитештерүчеләргә (шәхси ярдәмче хуҗалык алып баручы гражданнардан тыш) сөт комплекслары төзелешенә проект-смета документларын проектлаштыруга һәм аларга дәүләт экспертизасы үткәрүгә бәйле чыгымнарның бер өлешен каплау өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр (алга таба – алучылар, субсидияләр) бирү механизмын билгели.

2. Субсидияләр бирү тиешле финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турындагы Татарстан Республикасы законында каралган бюджет ассигнованиеләре һәм бу Тәртипнең 1 нче пунктында күрсәтелгән максатлар өчен бюджет акчасын алучы буларак Татарстан Республикасының Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгына (алга таба – Министрлык) билгеләнгән тәртиптә ирештерелгән бюджет йөкләмәләре лимитлары чикләрендә гамәлгә ашырыла.

3. Субсидияләр алучыларны сайлап алу критерийлары – түбәндәгеләр:

эшчәнлекнең төп төре – авыл хуҗалыгы җитештерүе, сөтчелек юнәлешендәге мөгезле эре терлек үрчетү;

400 һәм аннан күбрәк савым көтүе башларына исәпләнгән сыер саву залы белән яңа сөт комплексларын проектлаштыру һәм төзү, аларны 2018 – 2021 елларда эксплуатацияләүгә тапшыру.

4. Субсидия аны бирү турындагы килешү төзергә планлаштырыла торган көнгә кадәр 15 көннән артыграк булмаган көн эчендә субсидия алучының түбәндәге таләпләргә туры килү шарты белән бирелә:

закон белән билгеләнгән тәртиптә теркәлә һәм җитештерү эшчәнлеген Татарстан Республикасы территориясендә гамәлгә ашыра;

субсидия алучы – юридик зат бетерү, банкротлык процессында тормый, ә субсидия алучы – индивидуаль эшмәкәр үз эшчәнлеген индивидуаль эшмәкәр буларак туктатмый;

чит ил юридик затлары, шулай ук Россия юридик затлары (аларның устав (җыелма) капиталында Россия Федерациясенең Финанс министрлыгы белән раслана торган Салым салуның ташламалы салым режимы бирелә торган һәм финанс операцияләрен үткәргәндә мәгълүмат ачуны һәм бирүне күздә тотмый торган дәүләтләр һәм территорияләр (офшор зоналары) исемлегенә кертелгән дәүләт яки территория аның теркәлү урыны булган чит ил юридик затларның катнашу өлеше барысы бергә 50 проценттан артыграк булган) булып тормый;

Татарстан Республикасының башка норматив хокукый актлары нигезендә Татарстан Республикасы бюджетыннан бу Тәртипнең 1 нче пунктында күрсәтелгән максатларга акча алмый;

субсидияләрне, бюджет инвестицияләрен (шул исәптән башка хокук актлары нигезендә бирелгәннәрне) Татарстан Республикасы бюджетына кире кайтару буенча вакытында түләнмәгән бурычлары һәм Татарстан Республикасы бюджеты каршында вакытында түләнмәгән башка бурычлары булмый;

Россия Федерациясенең салымнар һәм җыемнар турындагы законнары нигезендә түләнергә тиешле салымнар, җыемнар, иминият кертемнәре, пеняләр, штрафлар, процентлар түләү буенча башкарылмаган йөкләмәләре булмый.

5. Субсидияләр бу Тәртипнең 1 нче пунктында күрсәтелгән чыгымнарның бер өлешен каплау өчен сөт комплекслары төзелешенә проект-смета документларын проектлаштыру һәм аларга дәүләт экспертизасы үткәрү буенча башкарылган эшләр (хезмәт күрсәтүләр) чыгымнарының 50 проценты исәбеннән чыгып бирелә.

6. Субсидияләр алу өчен субсидияләр алучылар түбәндәге документларны Министрлыкка тапшыра:

Министрлык боерыгы белән расланган форма буенча, үзләренең түләү реквизитларын һәм почта адресын күрсәтеп, шул исәптән түбәндәгеләр турында мәгълүматы булган субсидия бирү турындагы гаризаны:

субсидия алучы законнар белән билгеләнгән тәртиптә теркәлү һәм житештерү эшчәнлеген Татарстан Республикасы территориясендә гамәлгә ашыру;

субсидия алучы – юридик зат бетерү, банкротлык процессында булмау, ә субсидия алучы – индивидуаль эшмәкәр үз эшчәнлеген индивидуаль эшмәкәр буларак туктатмау;

субсидия алучы чит ил юридик заты, шулай ук Россия юридик заты (аларның устав (җыелма) капиталында Россия Федерациясенең Финанс министрлыгы белән раслана торган Салым салуның ташламалы салым режимы бирелә торган һәм финанс операцияләрен үткәргәндә мәгълүмат ачуны һәм бирүне күздә тотмый торган дәүләтләр һәм территорияләр (офшор зоналары) исемлегенә кертелгән дәүләт яки территория аның теркәлү урыны булган чит ил юридик затларның катнашу өлеше барысы бергә 50 проценттан артыграк булган) булып тормау;

субсидия алучы бу Тәртипнең 1 нче пунктында күрсәтелгән максатлар өчен Татарстан Республикасының башка норматив хокукый актлары нигезендә Татарстан Республикасы бюджетыннан акча алучы булып тормау;

субсидия алучының субсидияләрне, бюджет инвестицияләрен (шул исәптән башка хокук актлары нигезендә бирелгәннәрне) Татарстан Республикасы бюджетына кире кайтару буенча вакытында түләнмәгән бурычлары һәм Татарстан

Республикасы бюджеты каршында вакытында түләнмәгән башка бурычлары булмавы;

алучының салымнар һәм җыемнар турында Россия Федерациясе законнары нигезендә түләнергә тиешле салымнар, җыемнар, иминият кертемнәре, пенялар, штрафлар, процентлар түләү буенча үтәлмәгән йөкләмәләре булмавы;

проект оешмасы белән проект-смета документларын үтәүгә проект-тикшеренү эшенең смета кыйммәтен теркәп, шартнамә күчермәсен һәм үз-үзен җайга салучы оешмага проектлаштыруда катнашуга рөхсәтнамә кәгазенең алучы тарафыннан расланган күчермәсен;

төзелешкә җыелма смета исәп-хисабының алучы тарафыннан расланган күчермәсен;

башкарылган проект-тикшеренү эшләренең алучы тарафыннан расланган актларын;

проект документларына дәүләт экспертизасының уңай бәяләмәсе күчермәсен;

смета кыйммәтен билгеләү дөреслегенә тикшерү үткәрүгә дәүләт экспертизасының уңай бәяләмәсе күчермәсен;

товар йөкнамәсе, исәп-фактуралар, проект-смета документларын үткәрү һәм проект оешмасы белән проект-смета документларына дәүләт экспертизасы үткәрү турындагы шартнамәгә теркәлгән кабул итү-тапшыру акты күчермәләрен;

проект эшләре өчен түләүне һәм проект документларына дәүләт экспертизасы, шулай ук объектның смета кыйммәтен билгеләү дөреслегенә тикшерү үткәрүне раслый торган түләү йөкләмәләрен;

Министрлык тарафыннан расланган форма буенча субсидия бирү өчен белешмә кәгазе-исәп-хисапны.

Субсидияләр алучылар үз теләге белән алучының салымнар һәм җыемнар турында Россия Федерациясе законнары нигезендә түләнергә тиешле салымнар, җыемнар, иминият кертемнәре, пенялар, штрафлар, процентлар түләү буенча үтәлмәгән йөкләмәләре булмавын раслый торган салым органы белешмә кәгазен кертергә хокуклы. Әгәр дә әлеге документ субсидия алучы тарафыннан үз теләге белән кертелмәгән булса, Министрлык аны салым органыннан ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек итү тәртибендә соратып ала.

Тапшырылган документларның күчермәләре алучы тарафыннан раслана.

7. Министрлык:

субсидияләр бирү турындагы гаризаларны алар кергән көнне нумерлана, бау белән һәм мөһер сугып тоташтырыла торган журналда терки;

гаризаны теркәгән көннән эш көннәрендә исәпләнүче 15 көн эчендә:

тапшырылган документларның бу Тәртипнең 6 нчы пунктына туры килү-килмәвен карап тикшерә һәм субсидия бирү яки субсидия бирүдән баш тарту турында карар кабул итә;

Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы тарафыннан билгеләнгән бертип форма нигезендә субсидия бирү турында килешү төзи.

Субсидия бирүдән баш тарту өчен нигезләр – түбәндәгеләр:

документларны тулы булмаган комплектта тапшыру һәм алар бу Тәртипнең таләпләренә туры килмәү;

субсидия алучы тарафыннан тапшырылган мәгълүмат дөрес булмау;

бюджет йөкләмәләре лимиты булмау.

Бюджет йөкләмәләре лимиты җитәрлек күләмдә булмаган очракта, субсидияләр гаризаларны тапшыру чираты тәртибендә бирелә.

Субидияләрне бирүдән баш тарткан очракта, Министрлык бу пунктның өченче абзацында күрсәтелгән вакыт чыкканнан соң эш көннәрендә исәпләнүче биш көн эчендә алучыга баш тарту турында хәбәрнамә җибәрә.

8. Субсидия бирү турындагы килешүдә түбәндәгеләр күздә тотыла:

а) субсидия алучы тарафыннан субсидия бирү нәтиҗәлелеге күрсәткечләренә ирешү турындагы хисаплылыкны һәм Министрлык тарафыннан билгеләнгән башка хисапларны бирү формасы һәм вакытлары;

б) субсидия алучының (дәүләт (муниципаль) унитар предприятиеләрдән, устав (җыелма) капиталларында гавами-хокукый оешмалар катнашында хуҗалык ширкәтләреннән һәм җәмгыятьләреннән, шулай ук устав (җыелма) капиталларында мондый ширкәтләр һәм җәмгыятьләр катнашында коммерция оешмаларыннан башка) Министрлык һәм дәүләт финанс тикшерүендә тоту органнары тарафыннан субсидия бирү максатларын, шартларын һәм тәртибен субсидия алучы үтәвен тикшерүләрне гамәлгә ашыруга ризалыгы;

в) Министрлык һәм дәүләт финанс тикшерүендә тоту органнары тарафыннан үткәрелгән тикшерүләр нәтиҗәләре буенча аны бирү максатларын, шартларын һәм тәртибен бозу фактлары билгеләнгән очракта, субсидияләрне Татарстан Республикасы бюджетына кире кайтару тәртибе.

9. 2018 – 2021 елларда 400 һәм аннан күбрәк савым көтүе башларына исәпләнгән сыер саву залы белән яңа сөт комплексларын эксплуатацияләүгә тапшыру субсидия бирү нәтиҗәлелегенең күрсәткече булып тора.

10. Министрлык Татарстан Республикасы бюджеты акчасы белән баш эш итүче булып тора һәм Татарстан Республикасы Финанс министрлыгында ачылган үзенең шәхси исәбеннән субсидия бирү турында карар кабул иткәннән соң эш көннәрендә исәпләнүче 10 көн эчендә алучыларның исәп-хисап исәпләренә акча күчерүне гамәлгә ашыра.

Субсидияләрне күчерү өчен алучылар тарафыннан Министрлыкка тапшырылган бирелергә тиешле субсидияләр турындагы белешмә кәгазе-исәп-хисап нигез булып тора.

11. Бирелгән субсидияләр, бу Тәртип һәм субсидия бирү турындагы килешү белән билгеләнгән тәртипне һәм аларны бирү шартларын бозу фактларын ачыкланган очракта, шулай ук Министрлык һәм вәкаләтле дәүләт финанс тикшерүендә тоту органы тарафыннан үткәрелгән тикшерүләр фактлары буенча, шулай ук субсидияләр бирү нәтиҗәлелеге күрсәткечләренә ирешелмәгән очракта, Министрлыкның тиешле таләбен алган көннән 60 көн эчендә Татарстан Республикасы бюджеты керемнәренә бюджет законы нигезендә кире кайтарылырга тиеш.

12. Бу Тәртипнең 10 нчы пунктында күрсәтелгән акчаны Татарстан Республикасы бюджеты керемнәренә ирекле рәвештә кире кайтарудан баш тарткан очракта, алар Министрлык тарафыннан законнар нигезендә мәҗбүри тәртиптә түләттерелергә тиеш.

13. Министрлык һәм дәүләт финанс тикшерүендә тоту органнары алучыларның субсидияләр бирү шартларын, максатларын һәм тәртибен үтәвен тикшерүне законнар нигезендә гамәлгә ашыра.

14. Алучылар тарафыннан Министрлыкка тапшырыла торган документларның дөреслеге өчен җаваплылык тиешле вазыйфаи затларга һәм җитәкчеләргә йөкләнә.

15. Бюджет акчасын файдалануны тикшерүдә тоту Министрлык тарафыннан гамәлгә ашырыла.